**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 гыйнвар № 48

г. Казань

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен оештыру турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Россия Федерациясе субъектының лицензия комиссиясен төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе турындагы методик күрсәтмәләрне раслау хакында» 2014 ел, 28 октябрь, 658/пр боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен оештырырга.

2. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын (карарга теркәләләр) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 31 декабрь, б-2921 нче боерыгы белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына вәкилләр санына (квотасына) аны бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\48.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 29 гыйнвар,48 нче
карары белән расланды

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Нигезләмә Россия Федерациясе Торак кодексы, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 ел, 4 май, ФЗ-99 нчы, «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү турында» 2014 ел, 28 октябрь, 1110 нчы карары, Россия Федерациясе Төзелеш торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Россия Федерациясе субъектының лицензия комиссиясен төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе турындагы методик күрсәтмәләрне раслау хакында» 2014 ел, 28 октябрь, 658/пр боерыгы нигезендә эшләнде һәм Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе (алга таба – Лицензия комиссиясе) вәкаләтләрен, функцияләрен, эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Лицензия комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы законнарына, ведомстволар норматив актларына, бу Нигезләмәгә таяна.

3. Лицензия комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы гамәлгә ашыра.

## II. Лицензия комиссиясенең төп вәкаләтләре һәм функцияләре

4. Лицензия комиссиясенең төп вәкаләтләре булып түбәндәгеләр тора:

а) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия (алга таба – лицензия) бирү турында яки лицензия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итү;

б) квалификация имтиханын кабул итү;

в) лицензия тикшерүендә тоту чараларында катнашу;

г) лицензияне юкка чыгару турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү хакында карар кабул итү.

5. Лицензия комиссиясе үз алдында тора торган бурычларны үтәү максатларында түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

а) лицензия алуга дәгъва итүчеләр лицензияләр алу максатларында Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә ( алга таба – лицензияләүче орган) тапшырган документларны карый;

б) квалификация имтиханын кабул итүне һәм мондый имтихан беркетмәсен лицензияләүче органга җибәрүне тәэмин итә;

в) лицензия алуга дәгъва итүче керткән документлар һәм лицензия тикшерүендә тоту кысаларында лицензия бирүче орган үткәргән тикшерү нәтиҗәләре нигезендә лицензия бирү турында яки бирүдән баш тарту хакында (шул исәптән Лицензия комиссиясе катнашында) карар кабул итә;

г лицензия бирүче орган үткәрә торган лицензия тикшерүендә тоту чараларында катнаша;

д) лицензияләүче органның күпфатирлы йортлар турындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы лицензияләр реестрыннан чыгару хакындагы карарларына анализ ясый, шул исәптән лицензияне юкка чыгару өчен нигезләрне ачыклау һәм тикшерү максатларында;

е) лицензияләүче органның күпфатирлы йортлар турындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы лицензияләр реестрыннан чыгару хакындагы карарларын анализлау нигезендә лицензияне юкка чыгару турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү хакында карар кабул итә;

ж) лицензияләү мәсьәләләре буенча суд практикасын, лицензияләү тәҗрибәсен гомумиләштерә һәм анализлый, лицензияләү системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

з) лицензияләү мәсьәләләре буенча лицензияләүче орган һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итә;

и) Лицензия комиссиясе эше турындагы мәгълүматны ачуны тәэмин итә, шул исәптән кабул ителгән карарлар һәм карауга кабул ителгән документлар турында лицензияләүче органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

к) гариза бирүчеләрнең һәм кызыксынучы башка затларның коммерция серен тәшкил итә торган мәгълүмат белән эш иткәндә конфиденциальлекне саклауны тәэмин итә;

л) Лицензия комиссиясе утырышларында катнашу өчен лицензия алуга дәгъва итүчене, лицензиатны, экспертларны, лицензияләүче орган һәм дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм кызыксынучы башка затларны чакыра.

## III. Лицензия комиссиясе составы, аның әгъзаларын сайлау (билгеләү) тәртибе

6. Лицензия комиссиясе 14 әгъзадан тора.

7. Бары тик физик зат кына Лицензия комиссиясе әгъзасы була ала. Лицензия комиссиясе составына вәкилләр саны (квотасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

8. Лицензия комиссиясе составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый.

9. Лицензия комиссиясенең үз эшчәнлеген үзе җайга сала торган оешма яки эшчәнлеген торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмә, иҗтимагый торак тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыручы башка коммерциягә карамаган оешшмалар вәкиле булып торучы әгъзасы аның составыннан, Лицензия комиссиясе карарына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча түбәндәгеләр нигезендә чыгарыла:

а) Лицензия комиссиясе әгъзасының Лицензия комиссиясе рәисе исеменә язылган комиссия составыннан чыгару турындагы үтенечен үз эченә алган гаризасы;

б) торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге эшчәнлеген туктатканда йә Лицензия комиссиясе әгъзасы вәкиле булган оешма бетерелгәндә;

в) Лицензия комиссиясе әгъзасы Лицензия комиссиясе әгъзасы буларак аның кандидатурасын тәкъдим иткән оешмадан киткәндә.

10. Лицензия комиссиясе составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы карары белән делегат буларак кертелгән Лицензия комиссиясе әгъзасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча Лицензия комиссиясе әгъзасына аның кандидатурасын тәкъдим иткән җитәкченең Лицензия комиссиясе рәисенә язган рәсми хаты нигезендә алыштырылырга мөмкин.

11. Лицензия комиссиясе 3 (өч) елга төзелә. Әлеге вакыт үткәч, Лицензия комиссиясенең яңа составы төзелә, бу вакытта аның эшчәнлеге өзелмәскә тиеш.

12. Лицензия комиссиясе рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә. Лицензия комиссиясе рәисенең вәкаләтләре Лицензия комиссиясе вәкаләтләре вакыты чыкканнан соң, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча туктатыла.

13. Лицензия комиссиясе рәисе урынбасары Лицензия комиссиясенең беренче утырышында аның әгъзалары арасыннан сайлана.

14. Лицензия комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы Лицензия комиссиясе составыннан Лицензия комиссиясе рәисе урынбасары вазыйфасына берәр кандидат (шул исәптән үз кандидатурасын) тәкъдим итәргә, шулай ук аның вәкаләтләрен туктату турындагы мәсьәләне куярга хокуклы.

15. Лицензия комиссиясе рәисе урынбасары вәкаләтләрен туктау турындагы мәсьәлә Лицензия комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы башлангычы буенча утырышның көн тәртибенә кертелергә мөмкин.

16. Лицензия комиссиясе рәисе урынбасарын сайлау һәм аның вәкаләтләрен туктату турында карар, әгәр аның өчен Лицензия комиссиясенең тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларының яртысынан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

17. Лицензия комиссиясенең һәр әгъзасы тавыш биргәндә бер тавышка ия була. Лицензия комиссиясе рәисе урынбасарын сайлаганда бирелгән тавышлар тигез булса, иң күп тавыш җыйган кандидатлар буенча кабат тавыш бирү үткәрелә.

## IV. Лицензия комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләре

18. Лицензия комиссиясе рәисе:

а) Лицензия комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

б) Лицензия комиссиясе утырышларын үткәрү датасын һәм көн тәртибен раслый;

в) Лицензия комиссиясе утырышларында рәислек итә ;

г) Лицензия комиссиясе утырышлары беркетмәләренә кул куя;

д) үз компетенциясе чикләрендә Лицензия комиссиясе бурычларын үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка функцияләр башкара.

19. Лицензия комиссиясе утырышында Лицензия комиссиясе рәисе булмаганда аның функцияләрен Лицензия комиссиясе рәисе урынбасары башкара. Утырышта Лицензия комиссиясе рәисе һәм аның урынбасары булмаганда рәислек итү функцияләре катнашучылар арасыннан күпчелек тавыш белән сайлап куелган Лицензия комиссиясе әгъзасына йөкләнә.

20. Лицензия комиссиясе әгъзалары түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

а) Лицензия комиссиясе утырышы материаллары белән алдан танышып чыгарга;

б) Лицензия комиссиясе утырышларында катнашырга;

в) карала торган мәсьәләләрне тикшерү һәм карарлар кабул итү процессында тәртип һәм этика нормаларын сакларга;

г) үз позициясен аргументлар белән ныгытып бәян итәргә, кертелгән материалларга нигезле кисәтмәләр һәм өстәмәләр (алар булганда) бирергә;

д) кирәк булганда Лицензия комиссиясе утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә җибәрергә.

21. Лицензия комиссиясе әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Лицензия комиссиясе эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга;

б) Лицензия комиссиясе утырышларының көн тәртибенә бу Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә мәсьәләләр кертергә;

в) Лицензия комиссиясе утырышын җыюны таләп итәргә;

г) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм бу Нигезләмәдә каралган башка хокуклар гамәлгә ашырырга.

22. Лицензия комиссиясе әгъзалары Лицензия комиссиясе утырышлары барышында алган мәгълүматтан һәм үз урыннарыннан шәхси мәнфәгатьләрдә файдаланырга тиеш түгел, шулай ук аларның башка затлар тарафыннан шәхси мәнфәгатьләрдә файдаланылуына да юл куймаска тиеш.

23. Лицензия комиссиясендә әгъза булу җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашырыла.

## V. Лицензия комиссиясе эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү

24. Лицензия комиссиясе эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү Лицензия комиссиясе секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Лицензия комиссиясе секретарен Лицензия комиссиясе рәисе Лицензия комиссиясе әгъзалары арасыннан билгели.

25. Лицензия комиссиясе секретаре үз компетенциясе кысаларында:

а) дәгъва итүчедән квалификация имтиханына кертү турында гариза кабул итә;

б) лицензияләүче органнан дәгъва итүченең гаризасын һәм аңа теркәлә торган лицензия бирү өчен кирәкле документларны, лицензиягә дәгъва итүче керткән мәгълүматларга аларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү һәм планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча материаллар кабул итеп ала;

в) Лицензия комиссиясе утырышларының календарь планын эшләүдә һәм раслауда катнаша;

г) Лицензия комиссиясе утырышын үткәрү датасын һәм аның көн тәртибен килештерә һәм Лицензия комиссиясе рәисенә раслауга кертә;

д) Лицензия комиссиясе әгъзаларына һәм башка кызыксынучы затларга Лицензия комиссиясе утырышы датасы, урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә;

е) Лицензия комиссиясе утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча материалларны һәм документларны алдан эшкәртү һәм әзерләү эшен оештыра;

ж) кирәк булганда экспертларның Лицензия комиссиясе утырышында катнашуын тәэмин итә;

з) Лицензия комиссиясе әгъзаларына һәм кызыксынучы башка затларга Лицензия комиссиясе утырышы көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча материаллар җибәрүне тәэмин итә;

и) Лицензия комиссиясе әгъзаларына һәм кызыксынучы башка затларга Лицензия комиссиясе кабул иткән карарлар турында хәбәр итә;

к) Лицензия комиссиясе утырышы көн тәртибендәге мәсьәләләр турындагы материаллар буенча доклад ясый;

л) Лицензия комиссиясе утырышлары беркетмәләрен һәм алардан чыгармаларны рәсмиләштерә;

м) Лицензия комиссиясе утырышлары беркетмәләрен, Лицензия комиссиясе әгъзаларының шәхси эшләрен һәм башка материалларны архивка тапшыруны һәм саклауны тәэмин итә;

н) Лицензия комиссиясе эшен тәэмин итү өчен кирәкле башка вәкаләтләр гамәлгә ашыра.

## VI. Лицензия комиссиясенең эш тәртибе һәм аны оештыру

26. Лицензия комиссиясе утырышлары кирәк булуга карап, әмма айга кимендә ике тапкыр үткәрелә.

27. Лицензия комиссиясенең бергә җыелып үткәрелә торган утырышларын уздыру өчен кворум Лицензия комиссиясе әгъзалары санының иң киме ½ ен тәшкил итә. Бергә җыелып үткәрелә торган утырышта кворум булмаса, Лицензия комиссиясе рәисе утырышны башка көнгә күчерү турында карар кабул итә.

28. Лицензия комиссиясе утырышлары ачык була. Лицензия комиссиясе утырышында Лицензия комиссиясе әгъзалары булып тормаучы затлар да катнаша ала.

29. Лицензия комиссиясе әгъзаларына һәм кызыксынучы башка затларга утырышны үткәрү урыны, датасы, вакыты турында аны үткәрүгә 7 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә. Хәбәрнамә аны алырга тиешле затның аны алуын төгәл билгеләргә ярдәм итә торган теләсә нинди ысул белән җибәрелә, шул исәптән факсимиле-хәбәр, телефонограмма яки электрон почта ярдәмендә.

30. Лицензия комиссиясе үзенең эш регламентын эшли һәм раслый.

31. Лицензия комиссиясе беркетмәсе Лицензия комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

Лицензия комиссиясе утырышы беркетмәсенә Лицензия комиссиясе утырышында рәислек иткән зат кул куя.

Лицензия комиссиясе утырышы беркетмәсе Лицензия комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә лицензияләүче органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш. Лицензия комиссиясе утырышы беркетмәсенең күчермәсе Лицензия комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә лицензияләүче органга җибәрелергә тиеш.

32. Лицензия комиссиясе утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Лицензия комиссиясе утырышын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты;

б) Лицензия комиссиясе әгъзаларының һәмЛицензия комиссиясе утырышында катнашкан башка затларның гомуми саны һәм шәхси составы;

в) Лицензия комиссиясе утырышының көн тәртибе;

г) федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актларына һәм Лицензия комиссиясе карарлар кабул иткәндә таянган Лицензия комиссиясенең эчке документларына сылтамалар;

д) Лицензия комиссиясе утырышының көн тәртибе буенча карала торган мәсьәләләр буенча нәтиҗәләр.

33. Лицензия комиссиясе утырышы беркетмәсендә Лицензия комиссиясе кабул иткән карарлар һәм алар буенча тавыш бирү нәтиҗәләре булырга тиеш.

34. Лицензия комиссиясе утырышның көн тәртибендәге мәсьәләләре буенча карарларны ачык атвыш бирү юлы белән кабул итә.

35. Карар, әгәр утырышта катнашкан Лицензия комиссиясе әгъзаларының яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда Лицензия комиссиясе рәисе яки аны алыштыручы зат тавышы хәлиткеч була.

36. «Риза» яки «каршы» дигән тавышлар саны утырышта катнашкан затлар санының яртысыннан кимрәк булса, кабат тавыш бирү үткәрелә, моңа

«тоткарландым» дип тавыш бирү варианты керми. Кабат тавыш бирү турында карар Лицензия комиссиясе рәисе яки аны алыштыручы зат тарафыннан кабул ителә.

37. Лицензия комиссиясе әгъзалары тавыш бирү нәтиҗәләре бедә туры килми торган үз фикерләрен язма рәвештә белдерергә хокуклы. Бу факт беркетмәдә чагылдырылырга тиеш, ә тиешле документ утырыш материалларына теркәлә.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015ел, 29 гыйнвар, 48 нче
карары белән расланды

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча
Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссии рәисе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Арсланов Алмаз Ринат улы | «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар бердәмлеге» региональ коммерциягә карамаган партнерлыгының оештыру-хокук бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Барышев Александр Георгиевич | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Вәлиев Ленар Сәйдел улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Галиев Марат Һади улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Застела Михаил Юрьевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча) |
| Лихачёв Юрий Леонидович | Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе (ки-лешү буенча) |
| Матросова Кәүсәрия Ильяс улы | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил каршындагы эксперт советы әгъзасы (килешү буенча) |
| Низамов Фәнис Миңнеислам улы | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары |

| | |
|---|---|
| Романов Дмитрий Сергеевич | «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый тикшерүдә тоту региональ үзәге» коммерциягә карамаган партнерлыгы башкарма директоры (килешү буенча) |
| Фатыйхов Нәзиф Фарсый улы | «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар бердәмлеге» региональ коммерциягә карамаган партнерлыгы директоры (килешү буенча) |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары |
| Хәкимов Рөстәм Рәдиф улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының эксплуатацияләү һәм торак-коммуналь хуҗалык программаларын тормышка ашыру идарәсенә караган торак-коммуналь хуҗалык объектларын эксплуатацияләүне мониторинглау һәм төзекләндерү бүлеге башлыгы. |

F:\KARAR\2015\48 -1.docx